# Тиңдәш кисәкләр янында өтер кую

-тиңдәш кисәкләр үзара санау интонациясе, каршы куючы теркәгечләр белән килгәндә, җыючы һәм бүлүче теркәгечләр кабатланып килгәндә, алар янында өтер куела:

- *Ул көчле түгел, ләкин бик үткен, бик хәйләле.* (Г.Исхакый); *Укытасы авылга барып төштем кыш уртасында. Мәктәп мөдире бер олаучыга карый, бер - миңа.* (А. Гыйләҗев); *Авылның бөтен тормышы: кайгысы, шатлыгы, өмете ындырга күчте.* (Г. Исхакый);

# Аерымланган кисәкләр янында өтер кую

-Ярым хәбәрлеккә ия булган, ягъни фигыль һәм хәбәр сораулар белән белдерелгән, хәл кисәкләр ияртүче сүздән яраклаштырылган булса, алар өтер белән аерылалар. Бары тик урын хәле генә бу кагыйдәгә карамый: ул аерымланмый.

- вакыт хәле: *Минем җавапны алуга, ул килеп тә җиткән.* (М.Маликова);
- сәбәп хәле: *Бер егет, шул җыр яратуы аркасында, поездан да калган иде әле.* (М. Рафиков);
- максат хәле: *Талип, идарәгә керергә дип, ишеккә юнәлде.* (М.Хәсәнов);
- рәвеш хәле: *Кыз, башын игәц килеш, халык арасыннан читкә атлады.* (Ф.Садриев);
- күләм хәле: *Моңарчы бер дә авыр сүз ишетмәгән сабыйга, беркайчан да булмаганча бик күңелсез булып китте.* (Г.Галиев);
- шарт хәле: *Барып казларга кушылсаң, син ак каз була алмассың.* (Р.Миннулин);
- кире хәл: *Калсаң да бездән еракта, Күңелдә син һәрчакта.* (Г.Кашапов).

## Аныклагыч янында өтер кую

- аныклагыч аныклаучы теркәгечләр белән килсә өтер куела:
- *Кабинетның хуҗасы, ягъни мехбаза управляющие, Решевский дигән кеше иде.*

- зат алмашлыклары һәм рәвешләр белән белдерелгән кисәкләрне аныклап килсә өтер кула: *Аларны, төрле җирдән җыелган утызлап малайны, йөк машинасына утыртып, таш клубка алып килделәр.*

## Кереш сүзләр һәм кереш җөмләләр янында өтер кую

- җөмлә башында килгән эндәш сүзләр көчле тойгы белән әйтелмәсә, алардан соң өтер куела: *Садыйк ага, сезгә дә бераз җыеныбрак торырга кирәк.*
- җөмлә уртасында килгән эндәш сүзләр ике яктан да өтер белән ерыла: *Кара әле, Фәридә, минем монда вакыт җитәрлек, шушы бүрәнәләрдән сиңа өйлек бура бурап биримме?*
- җөмлә ахырында килгән эндәш сүзләр алдыннан өтер куела: *Хушлашырга безгә иртәрәк бит әле, иртәрәк бит әле, аккошлар!*
- җөмлә башында килгән кереш сүздән соң өтер куела: *Ниһаять, килеп тә җиттек;*
- җөмлә уртасында килгән кереш сүзләр ике яктан да өтер белән аерыла: *Минем ничек укуым, беренчедән, үземә кирәк;*
- җөмлә ахырында килгән кереш сүзләр алдыннан өтер куела: *Күзлек киярлек булган, минем күзләрем ул хәтле яхшы күрмиләр инде, әлбәттә;*

Тезмә кушма җөмләләрдә өтер кую

- тезү интонациясе, шулай ук каршы куючы теркәгечләр белән бәйләнешкә кергән җөмләләр арасына өтер куела: *Гөлүсәнең йөзенә кайнар кан йөгерде, күлләре акшарлы идәнгә текәлде.*
- бүлүче һәм җыючы теркәгечләр кабатланып килгәндә, җөмләләр арасына шулай ук өтер куела: *Янә күк күкрәде, янә яшен яшьнәде.* (М. Әмир); *Күпер дә артта калды, инешнең чылтыравы да ишетелмәс булды.* (Г.Бәширов)

Иярченле кушма җөмләләрдә өтер кую

- синтаксик иярчен җөмләнең хәбәре белән баш җөмләдәге иярткүче кисәк арасында нинди дә булса бер мөстәкыйль сүз тора икән, ике арага өтер куела: *Ул үзе дә, нәкъ Рәхим эшләгәнгә, ару-талуны белми эшләде бит.* (А.Расих);

# Аналитик иярчен кушма җөмләдә өтер кую

а) Бәйләүче чарасы мөнәсәбәтле сүз булып килгән җөмләдә тыныш билгеләре:

- иярчен җөмлә алдан килеп, баш җөмлә мөнәсәбәтле сүз белән башланса, ике җөмлә арасына өтер куела:*Хәзрәт бик ачыккан иде, шуңар күрә ул аш янына килеп утырмакчы булды.* (Ф.Әмирхан);

б) Бәйләүче чарасы ияртүче теркәгеч яки теркәгеч сүз булган җөмләләрдә тыныш билгеләре:

- иярчен җөмлә баш җөмләгә теркәгеч ярдәмендә ияреп килсә, алар арасына өтер куела: *Бигрәк тә Сабираның шатлыгы ташып бара, чонки аның өчен театрга барудан да зуррак бәйрәмнең булуы момкии дә түгел иде* (Ә.Еники);

- теркәгеч сүз (сорау алмашлыгы) бәйләүче чара булып килгәндә, иярчен җөмлә белән баш җөмлә арасына өтер куела: *Нәрсә ачылыр ул томан артында, миңа билгесез;*

- теркәгеч яки теркәгеч сүз иярчен жөмлә ягында килеп, баш җәмләдә мөнәсәбәтле сүз булган очракта, шулай ук ике арага отер куела: *Үчең нинди, теге шундый* (Мәкаль).

в) Интонация ярдәмендә бәйләнешкә кергән иярченле кушма җөмләдә тыныш билгеләре:

- нинди дә булса бер сүзне аныклап, җөмлә эчендә килгән иярүче компонент өтерләр белән аерыла:*Моннан ун ел элек, карты үлгәннән соң, балалар карчыкны калага тартып караганнар иде каравын...*(Ә.Еники);